РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

«13» декабря 2022

с. Тюлячи

КАРАР

№ 266

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елнын
24 ноябрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем
бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елнын 24 декабрендәге 559 номерлы «Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» карарына (08.02.2016 № 41, 29.01.2017 № 34, 20.06.2017 № 328, 29.12.2018 № 879, 16.11.2020 № 498, 31.12.2020 № 620, 15.02.2021 № 55, от 19.03.2021 № 124, 29.12.2021 № 325, 10.10.2022 № 197 карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча - 559 номерлы карар), түбәндәге редакциядә 2.1 пунктчасын бәян итеп, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.2.5. 2022 елның 10 октябреннән 2022 елның 31 декабренә кадәр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан

Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең гаиләләрендәге (гаилә әгъзаларын), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләре гаиләләрендәге (гаилә әгъзаларына) укучыларны, һәр уку көненә һәм ата-ана түләвенә 8 сум 30 тиен күләмендә субсидиядән торучы, кайнар туклану белән тәэмин итәргә. Әлеге категория укучылар өчен ата-аналар түләвен жирле бюджет акчалары исәбеннән түләргә.».

2. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ташламаны, хәрби комиссариатның мәгариф оешмасында укучының гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе, гражданның махсус хәрби операция чорында хезмәт узуы турында башка дәүләт органнарының раслаучы документлары нигезендә бирә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев